ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАР

18 март 2024 ел № 4

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 1 номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәтем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 09.11.2023 елгы 1 номерлы, "2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында" 09.11.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәтем торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 09.11.2023 елгы № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 09.11.2023 елгы № 2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау( су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, контракт буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, түбәләрне алыштыру) Кәтем торак пунктында;

2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту(тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар

хезмәтләре өчен түләү, М. Сәхбиев урамы буенча контракт буенча эшләр өчен түләү) ;

3) һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын Кәтем торак пункты территориясен төзекләндерү;

4) Кәтем торак пункты территориясен төзекләндерү (үлән чабу, контракт буенча эш өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу) :

5) Кәтем торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Кәкре Елга авыл җирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге Башлыгы И.М.Мухаметзянов